СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

29 август, 1998 ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 99 (8256) | Бәясе билгеләнгәнчә

## 30 август - Татарстан Республикасы мөстәкыйльлеге көне




### НОМЕРГА ТЕЛЕГРАММА

***Хөрмәтле Фатих Сәүбәнович!***

***Сезне һәм барлык район халкын олы бәйрәм - Республика көне белән кайнар котлыйм. Чын күңелдән Сезгә , районыгыз хезмәт ияләренә зур уңышлар, сәламәтлек, иминлек, Татарстанның якты киләчәге хакына яңа хезмәт казанышлары телим.***

**Хөрмәт белән - РФ ның Федераль җыелыш Дәүләт Думасы депутаты - Ә.ХАМАЕВ.**

## 1 СЕНТЯБРЬ - БЕЛЕМ КӨНЕ

### ИСӘНМЕ, МӘКТӘП!



*Менә тагын 1нче сентябрь - Белем көне җитте. Балалар, киң елмаеп, инде сагынырга өлгергән мәктәпләренә "Исәнме!" диләр. Туган Татарстаныбыз турында шигырьләр һәм җырлар яңгырый, ә яраткан укытучы үз тәрбияләнүчеләре кулыннан көзге чәчәкләр букеты кабул итеп ала. Сигезенче ел инде Белем көне Республика бәйрәме белән бергә билгеләп үтелә, һәм моннан һәр ике бәйрәм безнең өчен тагын да кадерлерәк, якынрак була бара.*

*Быел шәһәр һәм район мәктәпләре 10289 баланы кабул итәчәкләр, аларга 1640 укытучы белем һәм тәрбия бирәчәк. Белем бирүне заманча оештыру, программаларның төрлелеге, белем бирү шартларының яхшыруы, укытучыларыбызның югары һөнәри дәрәҗәсе - мәктәп укучысының һәрьяклы үсешен тәэмин итү буенча куелган зур һәм җитди бурычларны хәл итүдә төп ачкыч шулар.*

*Белем көне белән, кадерле дуслар! Яңа башлангычлар һәм кызыклы идеяләр сезгә!*

## НУРЛАТТА ДА, БОЛГАРИЯДӘ ДӘ...

Быелгы елны ЮНЕСКО "Балаларның сәламәтлеген кайгырту елы" дип игълан иткән иде. Чикләнгән җаваплылыктагы "Татнефть" - Нурлатнефтеразведка" җәмгыяте бу чакыруны кабул иткәндәй, ел балаларның сәламәтлеген ныгыту, аның кайгыртуга зур чыгымнар тотты. Июль аенда тугыз бала атна буена Болгариянең "Золотые пески" санаторий - курортында ял итте. Путевка бәясенең яртысын предприятие түли. Ә Нурлаттагы үзләренең санаторий - профилакториенда 244 бала ял итте һәм дәва алды. Биредәге шартлар да "Золотые пески"дан күпкә калышмыйдыр, мөгаен. Бу хакта киләсе саннарның берсендә укый аласыз.

**СПОРТ СӨЮЧЕЛӘРЕБЕЗНЕ ФУТБОЛ БУЕНЧА РАЙОН ЧЕМПИОНАТЫНЫҢ ИҢ ХӘЛИТКЕЧ МАТЧЛАРЫН КАРАРГА ЧАКЫРАБЫЗ.**

***28 августта*** - Кузнецов исем. - Зүзәй нефть промыселы (Каравыл Тавы).

***1 сентябрьдә*** - "Буровик" - Кузнецов исем. (стадион).

***2 сентябрьдә*** - НГДУ - Зүзәй нефть промыселы (стадион).

***5 сентябрьдә*** - НГДУ - Кузнецов исем. (стадион).

***Уеннар 18 сәг. тә башлана.***

## БӘЙРӘМГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

Татарстан Республикасы мөстәкыйльлеге көненә багышлап, 29 август көнне шәһәрнең үзәк мәйданында "Туган җирем Татарстан" дип исемләнгән массакүләм театрлаштырылган бәйрәм программасы тәкъдим ителә.

***15.00 сәгатьтән*** үзәк мәйданда сәүдә нокталары эшли башлый.

***16.00 сәгатьтә*** бәйрәмне тантаналы ачу.

***16.30 сәгатьтә*** яшь гаиләләрне һәм яңа туган баланы котлау.

***17.00 сәгатьтә*** үзешчән сәнгать көчләре тарафыннан әзерләнгән зур концерт. Шунда ук спорт - күңел ачу уеннары - шахмат, гир күтәрү, армрестлинг, аркан тарту, капчык киеп йөгерү һ.б. башлана.

***19.30 сәгатьтән 22 сәгатькә*** кадәр - дискотека.

Бәйрәмгә рәхим итегез, хөрмәтле нурлатлылар!

**Оештыру комитеты.**

## ҖАЕН ТАПТЫЛАР

Авыл эшчәннәре хезмәт хакын сирәк күрә. Ярый инде, үз хуҗалыгы ярдәмгә килә аңа, кирәк - ярагын колхоздан да яздырып ала. Әмма балалар мәктәпкә җыена башлагач, күпләр пошаманга төшә: замана балалары яхшыдан - яхшыны, матурдан - матурны күреп үсәләр, аларның күзе төшкән кием - салым, кирәк - яракны юнәтү ай - һай кыйммәткә төшә! Ә акча каян табасы? Бу хәсрәттән богдашкинолыларның быел башлары авыртмаска охшый. Менә август ахырында балаларны мәктәпкә җыярга дип, нефтебаза җитәкчелеге үз ярдәмче хуҗалыгы эшчәннәренә булышка килде. Алар һәр балага 200 сум исәбеннән балалы гаиләләргә акча бирделәр. Авыл халкы шат: димәк, балалар мәктәпкә яңа киемнән барачаклар.

***Игътибар: яңалык***

## ХУШЛАШЫРЛАР, АХРЫСЫ

Озакламый Нурлат сөт - май комбинаты үзенең бер җитештерүчесе белән хушлашыр, ахрысы. Җитештерүченең дә ниндие әле: җәйге айларда тәүлегенә 10 - 13 тоннага кадәр продукция озата торган "Киекле" ассоциациясе. Хушлашу сәбәбен ниндидер үзара килешмәү дип уйлый күрмәгез тагын. Эш шунда: шушы көннәрдә генә "Киекле" КХАсы үзенә сөт пастеризацияләү һәм аны пакетларга тутыру җайланмасы куйды. Хәзер ул җитештергән продукциянең 4 тоннасын арадашчысыз үзе пастеризацияләп, сатуга чыгарачак. Дөресрәге, ул моны "Камил - агро" фирмасы белән эшләячәк. Әлеге фирма биредә җиһазларны монтажлады, җитештерүче "Киекле" КХАсы белән чималны сатып алуга үзара килешү төзеде. "Камил - агро" - Киекле" уртак предприятиесе шулай туды. Предприятие һәр якның мәнфәгатен тигез шартларда үтәүне күздә тота, хуҗалык сөтнең һәр литрыннан тере акча алырга өметләнә. Аны сатуга икмәк заводы кибетләренә куярга сөйләшкәннәр.

Инде әзер продукциягә килсәк, ул сыйфаты ягыннан сөт - май заводы җитештергән сөттән шактый аермалы булачак. Бердән, аның майлылыгы 3,5 процент булачак, икенчедән, ул тетропак дип атала торган кәгазь пакетларга тутырылачак. Пакетларның һәм пастеризацияләүнең үзенчәлеге нәтиҗәсендә пакетлардагы продукцияне суыткычларда 1 айга кадәр саклау мөмкин булачак. Пастеризацияләүнең үзенчәлеге шунда: ул гадәттәгечә сөтне югары температурага җиткереп түгел, ә нурланышның күптөрле спекторлары (ультрофиолет нурлар) ярдәмендә пастеризацияли. Бу ысул барлык төр зарарлы микроорганизмнарны юкка чыгара, ә сыйфатлы матдәләр (мәсәлән, аксымны) саклый. Шуның белән сөтнең кулланучы өчен кыйммәте тагын да арта.Сөт республика дәрәҗәсендә ныклы тикшерү үткән, барлык стандарт таләпләргә җавап бирә.

Әйткәнебезчә, яңа җиһазның проект куәте - тәүлеккә 4 тонна сөт пастеризацияләп тутыру. Әлегә шуннан калган продукция элеккечә үк сөт - май заводына озатылачак. Әмма бу да озакка бармас, ахыры, хуҗалык чимал урнаштыруның тагын бер файдалы чыганагы белән сөйләшүләр алып бара. Шулай итеп, Киекленең комбинат белән бөтенләйгә хушлашуы ихтимал. Нишлисең, хәзерге чорда авыл шулай эзләнеп, табышка исәп тотып эшләсә генә яшәячәк. Бу яктан киеклелеләр янә районда беренчеләрдән булып хәрәкәткә килделәр. Ә хәрәкәттә бәрәкәт булмый калмас.

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**

## ӨЛКӘННӘРГӘ - МАХСУС КИБЕТ

***Пенсияләр түләүдә киеренке хәл туу сәбәпле, ТР Министрлар Кабинеты карары нигезендә Нурлат шәһәре һәм районы хакимияте башлыгы "Шәһәр һәм район пенсионерлары өчен пенсия хисабына товар җибәрү буенча кибет ачу һәм аны эшләтү турында" карар кабул итте.***

Карарны гамәлгә ашыру озакка сузылмады. "Чулпан" кибетенең сөт сату бүлеге тиз арада өлкәннәргә пенсия хисабына хезмәт күрсәтәчәк "Пенсионер" кибете итеп үзгәртелде.

Кибеткә товарны үз җитештерүчеләребез - сөт - май заводы, азык һәм ит комбинатлары, шикәр заводы, элеватор һәм башка предприятиеләр базар бәясеннән арзанрак итеп куячаклар. Максат изге: пенсия бирү озак тоткарланган очракта, өлкәннәр кирәк - яракларын пенсия хисабына юнәтсеннәр, азык - төлеккә кытлык кичермәсеннәр.

Кибет беренче көнен хезмәт күрсәтте инде. Ары таба биредә өлкәннәр заявкасы нигезендә көндәлек кирәк - яраклар, төзелеш материаллары да булдырырга ниятлиләр. Бу эш оештыручылардан байтак мәшәкать таләп итсә дә, өлкәннәрне икътисадый киеренкелек шартларында ярдәмсез калдырмау теләге болар белән исәпләшеп тормаска мәҗбүр итә.

Кибет тиз арада үз сатып алучыларын табар дип уйлыйбыз. Ул һәр көнне 8дән 17 сәгатькә кадәр (ял 13 сәгатьтән 14 сәгатькә кадәр) эшләячәк. Пенсионерларга үзләре белән пенсия таныклыгы, паспорт һәм пенсионер карточкасы алып килергә кирәк булачак. Соңгысын халыкны социаль яклау идарәсе бирә.

**С.НУРУЛЛИНА.**

# КЕМ ИҢ ОСТА БОРАУЛАУЧЫ?

Быел чикләнгән җаваплылыктагы "Татнефть - Нурлатнефтеразведка" җәмгыятенең һөнәри осталык буенча конкурсы августның кояшлы, матур бер көнендә үтте. Иртәнге 8дән үк Мамык авылындагы 928нче бораулау участогында ярышта катнашучылар җыелды. Нефтьче - бораулаучы өчен әһәмиятле сынау - конкурсны ачып, "ТН - ННР"ның баш технологы Р.Ш.Фәсхетдинов аларга котлау сүзе белән мөрәҗәгать итте.

Бүген безнең коллектив һәм, әлбәттә, нефть белән бәйләнешле башка предприятиеләр дә бик киеренке финанс хәлендә калдылар. Шуңа карамастан, күп еллар буе оештырыла торган конкурсны үткәрүдән баш тартырга уйламыйбыз, чөнки нәкъ авыр чорда производство дисциплинасы, һәр җитәкченең, белгечнең, хезмәткәрнең оешканлыгы, осталыгы зур әһәмияткә ия. Үз һөнәрен камил белүче кешеләре булган коллектив кына кыенлыклардан чыга алачак та.

Бу юлы да эшләп торучы бораулау участогына конкурска бораулау бригадаларыннан иң оста белгечләр белемнәре, тәҗрибәләре, осталыклары буенча сынашырга җыелды. Жирәбә тотканнан соң, конкурсның гамәли өлешенә тотындылар. Ярышның барышын компетентлы жюри күзәтте: куркынычсызлык техникасы кагыйдәләре үтәлмәсә, теге яки бу операцияне башкаруда хаталар җибәрелсә, бораулау вахтасына шунда ук балл киметелә. Бораулау технологиясе, бораулау җайланмалары һәм башкалар турында белемнәрне конкурсның теоретик өлеше ачыклады. Конкурс барышында нәтиҗәләр хәбәрдарлык тактасында яктыртылып торды.

Ике этаптан соң җиңүчеләр - һөнәре буенча иң осталарның исемнәре аталды. Беренче урынга С.Хәнипов бораулаучылар вахтасы чыкты. Икенче урынны В.Нестеров, өченчене В.Назаров вахталары алды. Конкурсның тантаналы өлешендә җиңүчеләргә кыйммәтле бүләкләр тапшырылды. Һөнәри осталык буенча бәйге моның белән генә тәмамланмады әле: ул - "Татнефть" АҖдә дәвам итәчәк.

**В.ЕРОМАСОВ,**
**куркынычсызлык техникасы буенча баш инженер урынбасары.**



*"Татнефтепром" ОАОсы Зүзәй нефть - газ чыгару промыселы каршында төзелеп килүче бу битум заводына зур киләчәк юрала. Ник дигәндә, ул елына үзе үк чыгарган 100 мең тонна нефтьне эшкәртеп, 60 мең тонна төзелеш һәм юл битумы, 30 мең тонна котельня - мич ягулыгы чыгарачак. Бу - танылган Карабаш заводы куәтеннән дә 2,5 тапкырга артыграк.*

*Шулкадәр продукцияне кая илтәрләр, дисезме? Анысы да уйланылган. Яңа завод продукциясен район гына түгел, республика, тирә - күрше регионнар да көтә. Әлегә бу продукцияне республика Уфа, Түбән Новгород якларыннан ташырга мәҗбүр иде. Ә нефть өстендә утырган Татарстан җире битумга аптырарга тиешме инде? (Хәзер исә аны тирә - күрше регионнарга сату да мөмкин булачак, дип өметләнәләр хуҗалар). Зүзәй ятмасындагы кара алтын шул ихтыяҗны капларга хезмәт итәчәк.*

*Быелның ноябреннән дә калмыйча заводны эшкә җибәрергә ниятлиләр. Төзелеш болай да озакка - 5 елга сузылган, аны мөмкин кадәр тизрәк эшкә җибәрү теләге һәркемне ашыктыра. Хәзер биредә нигездә КИП һәм автоматика җиһазлары куясы калган. Берочтан заводка кирәкле белгечләр әзерләү белән дә шөгыльләнәләр, бу эштә аларга тәҗрибә уртаклашырга Карабаш заводыннан да киләчәкләр.*

*Завод районга күп нәрсә бирәчәк. Шуларның берсе - яңа эш урыннары барлыкка киләчәк, хәзерге шартларда анысы да бик мөһим. Шуңа күптән түгел районда булып киткән ТРның Премьер - Министры Р.Н.Миннеханов заводка финанс ярдәме күрсәтү ниятен белдерде, "Татнефтепром" ОАОсы генераль директоры Р.К.Зарипов та төзелешне тизрәк очлау өчен бар көчне бирегә тупларга вәгъдә бирде.*

*Димәк, битум һәм мазутлы булыр көннәребез ерак калмый.*

*Рәсемдә: Зүзәй битум заводы шундый булачак.*

# ХАТЫН - КЫЗ БУЛДЫРА УЛ!

Иске Әмзә товарлыклы - сөтчелек фермасының уңышлы эшләгән еллары бар иде ул! Әмма соңгы елларда хуҗалыгыбызда терлекчелек күрсәткечләре түбән тәгәрәде, фермалардагы тәртип тә күзгә күренеп үзгәрде. Мөдирләр алышына торса да, хәлләр яхшырмады. Һәм моннан 3 айлап элек "Комбайн" КХАсы җитәкчелеге янә ферма мөдирен алыштырырга карар кылды. Тик кемне куярга? Уйлаштылар - киңәштеләр дә, Раиса Демидова исеменә тукталдылар. Урта мәктәпне тәмамлаганнан бирле шул хуҗалыкта, күп өлешен терлекчелектә эшләгән Раиса Анатольевна кандидатурасын терлекчеләр үзләре дә яклап чыктылар. Шулай итеп, коллектив белән җитәкчелекне Демидова үз кулына алды. Әлбәттә, өч ай әле ниндидер нәтиҗә ясар өчен зур срок түгел, әмма беренче уңай үзгәрешләр сизелә инде: хезмәт дисциплинасы яхшырды, биналар тәртипкә китерелә, коллектив та үз араларыннан үсеп чыккан җитәкче белән уртак тел табып эшли. Шулай барса, эшләр җайланырга тулы өмет бар!

**С.ФӘТХЕТДИНОВА,**
**хәбәрче.**

***Авыл яңарыш юлында***

# ДҮРТ КООПЕРАТИВНЫҢ ӨЧ ТАРИХЫ





***"Руслан" кооперативы***

## «СӨТ - СУМ БУЛСА, ДУҢГЫЗ - ВАЛЮТА»

Кыска гына идарә итү чорында да "Руслан" кооперативы рәисе Мәҗидулла Хәбибуллович Хәмидуллин бу хакыйкатьне аңларга өлгергән. Яшәү рәвеше шуңа өйрәткән аны. Хезмәт хакын дуңгыз баласы белән бирә, 259 бала таратылган, запас частьне - дуңгызга юнәтә. Шуңа бүген 500 башлап исәпләнгән дуңгызларны якын киләчәктә 5 меңгә җиткерергә ниятлиләр. Реаль түгел дисезме? "Руслан"да алай уйламыйлар. Шул ният белән алар дуңгызчылыкны нигезеннән күтәрүгә алынганнар. Март аеннан ук дуңгыз караучылар белән натуралата түләү тәртибен сөйләшкәннәр һәм беренче нәтиҗәгә ирешкәннәр дә: март балалатуында 1 ана дуңгыздан 8 бала алганнар, килешү нигезендә, аның 6сы - кооперативка, 2се - терлекчегә бирелгән. Июль балалатуында бу сан 9га җиткән.

Бер дигән итеп 50 башка җәйге лагерь төзегәннәр. Материалны янә дә Бутаихадан дуңгыз балаларына алмаштырып алганнар. Ике бинага капиталь ремонт ясаганнар, өченчесенә бара әле. Дуңгызларга торыр урын булачак. Ә азык? "Зооветснаб"тан үз шартлары белән дару килешкәннәр. Терлекчеләр дару үләннәре, кычыткан җыйганнар, яфрак азык әзерләгәннәр. Фураж белән нишләргә? Анысының да җаен тапканнар. 1 мең куб. метр делянкалары бар. Шуны сатып, фураж һәм катнаш азык юнәтергә җыеналар. Тагын да үз чыганаклары буенча, билгеле. Ничек кенә итсәләр дә, 1 гыйнварга чучкаларның баш санын 300гә арттырырга уйлыйлар. "Дуңгыз - валюта" икән, валюта курсы күтәрелә торган заманда чын хуҗа шулай эшләргә тиеш!

Әлбәттә, "сумнарны" да читкә тибәрергә уйламыйлар. Савым сыерларын кабул итеп алгач, ректаль тикшерү үткәрәләр. 103 баш сыер, 85 тана бар икән, шуның 42се - кысыр. Яшьләренә килгәндә, күбесе 15 - 16 яшьлекләр.

Кичекмәстән, көтүне яңарту эшенә керешәләр. Чабаксардан нәселле үгезләр сөйләшәләр. 67 баш бозылган сыерны интенсив симертүгә куялар, аннан аларны сатып нәселле таналар алырга телиләр. Ә савучыларга кытлык юк, чөнки алар хезмәтенә түләүне иң беренче чиратта кайтарталар. Шуңа 5 - 6 кеше фермага килергә чират тора.

Көтүне яңарту белән бергә, сөт җитештерү технологиясен заманча оештыруга да әһәмият бирәләр. 3 ферма бинасында да хәзер реконструкция бара. Аны бәйләүсез ысул буенча асрауга көйлиләр. Кыш көнне салам тарттыру мәшәкатеннән котылу өчен, "Агрохимсервис" АҖ аларга махсус җиһазлап машина биргән, саламны ферма янына туплап калдырачаклар. Тик менә тапшырылган продукция өчен акча алырга гына күренми: сөт - май комбинатында электән җыелган 450 мең бурычлары бар булып чыккан. Менә хәзер, нәкъ алар аякка басарга тырышканда, сөтләрен (килограммын 1 сум 20тиеннән сату җаен тапканнар) үз чыганаклары буенча сатарга рөхсәт бирсәләр икән дә бит!

Менә шуңа кооператив җитәкчесе М.Хәмидуллин: "Мөстәкыйльлек эшләгәндә генә түгел, җитештергәнне сату, кирәкне табу кебек мәсьәләләрдә дә булсын иде ул",- ди. Ул бар йөрәге белән ышана: алар җирлеге өчен хуҗалык итүнең бары хәзерге ысулы кулай. Барысы да әлегә үзара ышанычка, вәгъдәгә, шәхси авторитетка корылган, шуңа да ул үзе боларны ничек тә җуймаска тырыша. "Агрохимсервис" белән үзара мөнәсәбәтләренә шатлана: алар кемнәрдер кебек үз проблемаларын Елаурга салырга, аннан соңгысын ташырга килмәгәннәр. Ярдәмче хуҗалык аларга техника, ашлама, башкасы белән ярдәм итә, киңәш бирә, үзара мөнәсәбәтләрне координацияли һәм нәтиҗәдә хуҗалык өчен зур авторитет булып тора.

Кооператив җитәкчелеге халык мәнфәгатен хәл итүне дә беренче планга куя. Хезмәт хакы да бирәләр икән. Алар хәтта элекке бурычларының 200 мең сумын да түләргә җай тапканнар. Әлбәттә, бүгенге урман - дуңгыз - терлек механизмы хуҗалык итүнең башлангыч чорында, чарасызлыктан гына сайланган нәрсә. Хәмидуллин нык ышана: килер бер көн, шул ук дуңгыз баласы "валюта" төсле түләү чарасы булмас, ә чын валюта китерер. Бик ихтимал!

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**



**Рәсемнәрдә: "Руслан" кооперативы механизаторы Владимир Мензелеев ДТ - 75 тракторында көзге чәчүдә тырышып эшли; дуңгызларның җәйге торагы.**

**Н.АЗИЗОВ фотолары.**

**(Ахыры киләсе санда).**

# «ИРТӘН ТОРЫП БАЛАЛАР МӘКТӘП ТАБА БАРАЛАР...»

Г.ТУКАЙ



## ФОРМАЛАРНЫҢ ТӨРЛЕСЕ КИРӘК...



Казан базарларында өлкән класс укучылары диңгез артыннан кайткан "спандекс" костюмнарын киеп карыйлар - билбау, төймәләр, кесәләр... Әйе, тонык коңгырт күлмәкләр белән бөрмәле алъяпкычлар бик еракта калды: инде ничәнче ел ата - аналар җәй уртасыннан башлап мәктәп формасы эзли башлыйлар. Хәер, бу мәсьәләдә проблема юк быел - базар сатып алучы ихтыяҗын тиз шәйләп ала. Теләсәң кайсын сайлап ал. Менә бездә бу җәһәттән хәлләр ничек тора икән?

Район мәгариф бүлегендә бу хакта үз позицияләрен ике сүз белән болай аңлаттылар: форма булырга тиеш. Бөтен мәктәпкә бер төрле булмаса да, класска бер төрле. Хәзер модельләр аз түгел - зәвыгыңа һәм мөмкинлегеңә карап. Дөрес, гаиләләрдә акча кытлыгы - монысы аңлашыла, тик бу мәсьәләдә төрле юлларны эзләүчеләр бар. Мәсәлән, Зирекле мәктәбе дирекциясе район балалар - яшүсмерләр үзәгенә тегәргә заказ биргән. Комплектларны ата - аналарның хезмәт хакы исәбенә теккәннәр. Шулай итеп, биредәге укучыларның киемнәре көнләшерлек булачак. Шәһәр мәктәпләре арасында укучыларның кыяфәтләрен килешле итү буенча 2нче мәктәп беренчелекне ала әлегә. Мәктәпнең уку - укыту эшләре буенча директор урынбасары Татьяна Николаевна Маслова әйтүенчә, биредә параллельләр буенча бердәй форма кертергә тырышалар. Тулаем мәктәпкә бердәй форма кертү гамәлгә ашмаслык хәл, чөнки анда барлыгы 1300 укучы. 11 "б" класс кызлары дәресләргә контрастлы төс белән тулыландырылган кызыл костюмнардан киләчәк, ә егетләр карадан. 11 "г" егетләре классик ак - кара төсләрне сайлый, ә кызлар зәңгәр джинс сарафан белән ак "водолазка"ны кулай күрәләр. Мәшәкате азрак булыр дип, ата - аналар да каршы төшмәгән.

Безнең газета укучылар арасында үткәргән кечкенә әңгәмәдән аңлашылганча, мәктәпкә форма кертүгә беркем дә каршы түгел, киресенчә ул укучыны тәртипкә, пөхтәлеккә өйрәтә. Зәвык тәрбияли, матурлыкны яратуга өйрәтә, диләр. Әниләрне артык эштән азат итә. Шуларга өстәп, матур да бит әле. Инде гаиләдә форма алырлык акча булмаса, өсте - башы чиста булсын - иң мөһиме шул.

Т.АЛЕКСЕЕВА.

Н.АЗИЗОВ фотоэтюды



## ШАХМАТ ҺӘРКЕМ ӨЧЕН ДӘ

1998 елның 1нче сентябреннән балалар - яшүсмерләр физик хәзерлек клубының шахмат һәм шашка секциясендә занятиеләр башлана. Монда мәктәп яшендәге балалар йөри ала.Занятиеләр ике сменада үткәрелә.

Беренче смена иртәнге сәгать 8дән 11гә кадәр, икенче смена көндезге 1дән кичке 4кә кадәр шимбә һәм якшәмбедән кала һәр көнне эшли. Секциягә йөрү өчен ата - аналардан директор исеменә гариза, медицина белешмәсе кирәк.



Шахмат һәм шашка секциясеннән кала, монда баскетбол, волейбол, футбол, чаңгы, җиңел атлетика, милли көрәш һәм каратэ түгәрәкләре эшли. Секцияләрнең эш шартлары турында ДЮКФПның тренерларыннан белешергә була.

Ата - аналар игътибарына: түгәрәкләргә йөрү түләүсез.

А.КОСТИН,
ДЮКФПның шахмат буенча тренеры.

*Шәфкатьлелек*

# КАН ДА ЖӘЛ ТҮГЕЛ

Бер акыл иясе "игелек эшлә дә суга ташла" дигән. Ягъни игелек ит тә оныт, аны үзеңә игелек итеп кире кайтару турында уйлама да, шелтә дә белдермә. Бүген "син - миңа, мин - сиңа" дигән фәлсәфә яшәешкә, кеше аңына тирәнтен үтеп кергәндә бу тәкъбир көлке тоеладыр, мөгаен. Тик нәтиҗәләр чыгарырга ашыкмагыз, иң кыен вакытта иптәшенә ярдәмгә килеп, аны чир тырнагыннан алып калыр өчен үз каннарын кызганмый торган кешеләр бар әле. Бу хакта безгә район үзәк хастаханәсенең кан салу бүлегеннән хәбәр иттеләр.Дөрес, факт гадәттән тыш хәл түгел, кеше мөнәсәбәтләрендә ул табигый булырга тиеш, дип әйтергә мөмкин. Әмма бүген мондый хәлләр еш очрамый шул.

РСУда штукатур - буяучы булып эшләүче Н.ның гаиләсе, ике баласы бар. Каты авыру нәтиҗәсендә ул эчке кан югалту кичерә, ашыгыч рәвештә аңа донор каны салырга кирәклеге ачыклана. Кызганычка каршы, соңгы вакытта хастаханәдә кан кытлыгы бик нык сизелә. Медицина хезмәткәрләре тиз арада авыруның эш урыны белән бәйләнешкә керәләр. "Бәхеткә, РСУ җитәкчелеге хәлне тиз аңлады, үз предприятиеләрендә эшләүче кешене кайгыда ялгызын калдырмады", - диләр кан салу бүлегендә. Иптәшләренә ярдәм кулы сузарга берничә хатын - кыз теләк белдерә, җитәкчелек аларны хастаханәгә илтергә автобус та бирә. Ике кеше - Миннегаян Сәйфетдинова һәм Фәһимә Газизованың каны яраклы дип табыла. Бу гүзәл затларда иптәшлек рухы, бушлай игелек кылырга әзерлек булуына куанасы гына кала. Хәер, алар үзләре ул хакта артык уйга бирелмиләр дә, бары тик иптәшләре терелсен, балалар анасыз калмасын гына, диләр.

Ф.ЗЫЯТДИНОВА.

## ЯЗМЫШ

*Ник һаман да язмыш мине*
*Уйната дулкынында?*
*Нигә генә ташландым соң*
*Хисләрем упкынына.*
*Дулкыннары мине һаман*
*Кагып - сугып йөдәтә.*
*Яшәү -үзе мәктәп икән,*
*һәр гамәле өйрәтә.*
*Әллә үзем куркак микән*
*Табалмыйм һаман юлны?*
*Ни дисәң дә, кеше һаман*
*Шушы язмышның колы.*

*И.Низаметдинова.*
Кизләү авылы.

## АҢЛАМАДЫҢ...

*Аңламадың теләсәм дә*
*Аңлатырга барын да.*
*Әллә гаеплемен микән*
*Мин дә синең каршыда?*
*Ничек итеп аңлатыйм соң*
*Язмыш шаяртуларын?*
*Җирдә миңа яшәү өчен*
*Дөнья тараюларын?*
*Аңлатмыйм, аңламассың күк*
*Сабырлыкларым сына.*
*Ләкин мин дә синнән башка*
*Яши алмамын сыман.*




## КОТЛЫЙБЫЗ!

Яңа Иглай авылында яшәүче **тормыш иптәшем, әтиебез, зур әтиебез Минабетдин Кыяметдин улы Фәйзуллинны** олы юбилее белән котлыйбыз.

Күңел күгең һәрчак аяз булсын,
Килмәсеннәр сагыш - борчулар.
Ныклы сәламәтлек юлдаш булсын,
Аннан кадерлерәк нәрсә бар?!

**Тормыш иптәшең, кызың, киявең, улларың, оныкларың.**




## БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА. БЕЛДЕРҮЛӘР.

### САТАБЫЗ

**Ашыгыч төстә бик әйбәт хәлдәге ВАЗ - 21083.**
Адрес: Гыйматдинов ур., 60 - 17.

***

**6 х 4ле чанада гараж, "Локомотив" ширкәтендә сутый дача, коесы бар.** Тел.: 2-15-42, 5-12-44.

***

**6х5ле кирпеч гараж.** Тел.: 5-10-51.

***

**Бер бүлмәле фатир.** Адрес: Завод ур., 24-9 яки Бөгелмә шәһәре, К.Маркс ур., 11.

***

**Тәрнәс авылында йорт.**
А.А.Космачевка мөрәҗәгать итәргә.

***

**Чистарту корылмалары янында гараж, базы бар.** Тел.: 5-44-23.

***

**Әйбәт хәлдәге "ИЖ-Юпитер-5" мотоциклы.**
Адрес: Октябрьнең 60 еллыгы ур., 9-18, теләсә кайчан.

***

**Совет урамындагы 49нчы йортның ярты ягы.**
Теләсә кайчан мөрәҗәгать итәргә.

***

**1987нче елгы ВАЗ-2108.**
Адрес: Дружба ур., 60-46, тел.: 5-29-66.

### *АЯК КИЕМНӘРЕ САТЫЛА*

***Район мәдәният йортында 3нче һәм 4нче сентябрьдә Ульян күн фабрикасы иртәнге 8дән кичке 4кә кадәр аяк киемнәре сата. 07.09.93 елда бирелгән Б - 103136 номерлы лицензия.***

### КЫЙММӘТЛЕ ДАРУЛАР

#### СӘДӘФЛЕ МУМИЕ, ГРАНУЛАДА ЖЕНЬ-ШЕНЬ, ПИХТА ҺӘМ ШАЛКАН МАЕ.

**Женьшень** неврастения, йөрәк неврозы, баш авырткаңда кулланыла.

**Мумие** ашказаны язвасы, бавыр, бөерләр, сидек куыгы авыртканда файдаланыла.

**Алисат** (патша сәдәфләре) гипертония вакытында кан басымын төшерә.

**Анкир** - диабетларны дәвалый, авырлыкны киметү, организмнан шлаклар һәм токсик матдәләрне куарга билгеләнгән.

Шулай ук **магнит билбаулары, беләзекләр, аслыклар** сатабыз.

***Бу даруларны сез район үзәк хастаханәсе поликлиникасында бары бер көн - 2 сентябрь көнне 9 сәгатьтән 12 сәгатькә кадәр ала аласыз. Барлык препаратларның да сертификаты бар.***

Лицензия номеры 000458.

### САТАБЫЗ ЯКИ АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Шәһәр үзәгендәге барлык уңайлыклары белән сутый участогы булган 6 почмаклы агач йортны сатабыз яки Нурлат шәһәрендә, Яр Чаллыда ике бүлмәле фатирга алмаштырам.**
Адрес: Ломоносов ур., 20б, тел.: 2-10-05.

***

**Мордовия Республикасының Кадошкино шәһәре тибындагы эшчеләр поселогында коттеджның яртысын Нурлаттагы торакка алмаштырам. 1988нче елгы ВАЗ-21047, шикәр заводы ягында дача сатам.**
Тел.: 5-33-89 (эш).

### АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Шәһәр үзәгендәге ике берәр бүлмәле фатирларны - өч бүлмәлегә.** Тел.: 5-19-86.

***

**Чапаев урамындагы 19нчы йортны - өстәмә түләп ике бүлмәле фатирга.** Кичке 6дан соң мөрәҗәгать итәргә.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**Әйбәт төзүчеләр турында бушлай информация бирәм.** Тел.: 5-16-25 (Нәҗип).



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

Учредительләр:Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.
Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*ГазетаТатарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2353 данә. 3360